| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ГЛАВА СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Әлмәт ав. **КАРАР**

«05»ноябрь 2024 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елның 18 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Октябрь урамы, 19нчы йорт адресы буенча урнашкан Иске Әлмәт авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылында халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру белән Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәмәүче гражданнардан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юл полотносы профилен үзгәртеп, юлларны карап тоту, юлларны карап тоту, вак таш сатып алу, вак таш салу өчен хезмәт күрсәтүләр),

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә грейдерлау һәм алга таба вак таш салу өчен тыгызланган нигез салу хезмәтләре күрсәтү,шул исәптән сезонлы карап тоту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы торак пункты территориясен төзекләндерү);

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында района http://nurlat.tatarstan.ru, Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов